КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 февраль г.Казань № 91

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы өстәмә акчалата түләүләр турында» 2013 ел, 6 февраль, 77 нче карары белән расланган Дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының халыкка туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина, фармацевтика хезмәткәрләренә һәм педагогика хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга бщйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы өстәмә акчалата түләүләр турында» 2013 ел, 6 февраль, 77 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 октябрь, 717 нче; 2017 ел, 18 гыйнвар, 13 нче; 2018 ел, 13 февраль, 83 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының халыкка туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина, фармацевтика хезмәткәрләренә һәм педагогика хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга бщйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен иң чик финанслау күләмнәрен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерә.»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты тарафыннан ачылган» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин